КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 17 май г.Казань № 604

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль эшкуарлар реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, яисә 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 12 октябрь, 971 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль эшкуарлар реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, яисә 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 12 октябрь, 971 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 17 ноябрь, 1086 нчы, 2022 ел, 08 сентябрь, 968 нче, 2022 ел, 20 октябрь, 1116 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «яисә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына» сүзләрен «һәм (яисә) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «яисә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына» сүзләрен «һәм (яисә) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Социаль эшкуарлар реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына яисә 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибендә (алга таба - Тәртип):

исемендә «яисә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына» сүзләрен «һәм (яисә) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына» сүзләренә алмаштырырга;

1.2 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«заявка бирүче – «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән, социаль предприятие булып торган һәм (яки) 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) шәхси эшкуар һәм юридик зат, 25 яшькә кадәрге бер яисә берничә физик затның устав (җыелма, акционер) капиталында катнашу өлеше (суммар өлеше) 50 проценттан артып киткән, белешмәләр әлеге Тәртип шартларына туры килә торган грант алучыларны сайлап алуда катнашуга вәкаләтле органга гариза биргән кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән, моңа кадәр әлеге грантны алмаган кече яисә урта эшкуарлык субъекты;»;

1.2 пунктның унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«конкурс комиссиясе – грант бирү максатларында заявкаларны карауны һәм бәяләүне, шулай ук грант алучыларның проектны гамәлгә ашыруга һәм (яисә) проектны гамәлгә ашыруга тотылган грант күләме чикләрендә чыгымнарны гамәлгә ашыруга үзгәрешләр кертүгә чыгымнарның юнәлешләре һәм (яисә) исемнәре буенча суммаларны яңадан бүлү буенча мөрәҗәгатьләрен карауны гамәлгә ашыручы коллегиаль киңәшмә орган;»;

1.4 пункттагы унбишенче абзацка «килешү предметы транспорт чарасы булса, «Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре турында» 2021 елның 2 июлендәге 297-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясында билгеләнгән үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләреннән тыш, лизинг, сублизинг шартнамәсе буенча түләүләр түләү»;

1.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Грант турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – Бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

2.1 пунктта:

беренче абзацта «15 енә « сүзләрен «1 енә» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «1» санын «3» санына алмаштырырга;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше

барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

2.2 пунктта:

беренче абзацта «15 енә « сүзләрен «1 енә» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «, - ике вариантның берсенә:» сүзләрен төшереп калдырырга;

бишенче абзацта «1)» санын төшереп калдырырга, «10 декабрь» сүзләрен «31 декабрь» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «2)» санын төшереп калдырырга;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«кече һәм урта эшкуарлык субъекты 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик зат тарафыннан төзелгән (25 яшькә кадәрге физик зат (25 яшьне кертеп) грант алу өчен документлар тапшыру вакытына индивидуаль эшкуар яисә юридик зат буларак теркәлгән, 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп)  бер яисә берничә физик зат устав (җыелма, акционер) капиталында катнашу өлеше (суммар өлеше) 50 проценттан артып китә);»;

3.1 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затның шәхесен таныклый торган документ күчермәсе   (25 яшькә кадәрге физик зат (25 яшьне кертеп) грант алу өчен документлар тапшыру вакытына индивидуаль эшкуар яисә юридик зат буларак теркәлгән, 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп)  бер яисә берничә физик зат устав (җыелма, акционер) капиталында катнашу өлеше (суммар өлеше) 50 проценттан артып китә);»;

3.2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алу үткәрелергә планлаштырыла торган айның 1 енче көне хәленә карата Россия Федераль Салым хезмәтенең «Салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычларын үтәве турындагы белешмә кәгазе формасын, аны тутыру тәртибен һәм аны электрон формада тапшыру форматын раслау хакында» 2022 елның 23 гыйнварындагы ЕД-7-8/1123@ номерлы боерыгы белән билгеләнгән форма буенча салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү йөкләмәләре үтәлүе турында салым органы тарафыннан бирелгән белешмә кәгазе яки сайлап алу үткәрелергә планлаштырыла торган айның 1енче көне хәленә карата Россия Федераль Салым хезмәтенең «Салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча исәп-хисапларның торышы турында белешмә кәгазьләре формаларын, аларны тутыру тәртибен һәм белешмә кәгазьләрен электрон рәвештә

бирү форматларын раслау хакында» 2021 елның 6 августындагы ЕД-7-19/728@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча оешмаларның һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча исәп-хисаплары торышы турында белешмә кәгазе.»

5.7 пунктта:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«грант бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәсенең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);».

алтынчы абзацта «өстәмә килешү» сүзләрен «өстәмә килешүләр» сүзләренә алмаштырырга;

5.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.12. Проектны гамәлгә ашыру чорында грант алучы, әмма проектны гамәлгә ашыру срогы тәмамланганчы 15 көннән дә соңга калмыйча проектны гамәлгә ашыру чыгымнары юнәлешләре һәм (яисә) исемнәре буенча суммаларны яңадан бүлү һәм (яисә) проектны гамәлгә ашыру чыгымнары исеменә алынган грант күләме чикләрендә үзгәрешләр кертү өчен вәкаләтле органга мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Чыгымнар исеменә үзгәрешләр кертү килешүләрдә билгеләнгән товарларның маркаларын, һәм (яисә) модельләрен, һәм (яисә) сериясен үзгәрткәндә рөхсәт ителә.

Проектны гамәлгә ашыруга чыгымнар юнәлешләре һәм (яисә) исемнәре буенча суммаларны яңадан бүлешү һәм (яисә) проектны гамәлгә ашыруга чыгымнар исеменә үзгәрешләр кертү өчен вәкаләтле органга грант алучының мөрәҗәгатенә нигез булып базар бәяләре үзгәрүгә һәм (яисә) конкрет товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр җитештерүне туктатуга бәйле рәвештә, килешүдә күрсәтелгән грант акчаларын тоту мөмкинлеге булмау тора.

Вәкаләтле орган грант алучының мөрәҗәгате кергән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 20 көн эчендә мөрәҗәгатьне карап тикшерү буенча конкурс комиссиясе утырышын оештыра.

Конкурс комиссиясе әлеге пунктның алтынчы абзацында билгеләнгән срокта грант алучының мөрәҗәгатен карый һәм проектны гамәлгә ашыруга чыгымнарны юнәлешләр һәм (яисә) исемнәр буенча суммаларны яңадан бүлү турында яисә проектны гамәлгә ашыруга чыгымнар исеменә үзгәрешләр кертү хакында карар кабул итә һәм беркетмәне рәсмиләштерә.

Вәкаләтле орган беркетмә төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә грант алучыга кабул ителгән карар турында хәбәр итә.

Конкурс комиссиясе проектны гамәлгә ашыруга чыгымнарның юнәлешләре һәм (яисә) исемнәре буенча суммаларны яңадан бүлү һәм (яисә) проектны гамәлгә ашыру чыгымнары исеменә алынган грант күләме чикләрендә үзгәрешләр кертү турында карар кабул иткән очракта вәкаләтле орган грант алучы белән конкурс комиссиясе карар кабул иткән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән типлаштырылган форма буенча килешүгә өстәмә килешү төзи.

Проектны гамәлгә ашыруга чыгымнарның юнәлешләре һәм (яисә) исемнәре буенча суммаларны яңадан бүлүдән һәм (яисә) проектны гамәлгә ашыру чыгымнары исеменә алынган грант күләме чикләрендә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен нигез булып грант алучының килешүдә каралмаган чыгымнар

юнәлешләре һәм (яисә) исемнәре буенча суммаларны яңадан бүлү турында мөрәҗәгате тора.»;

түбәндәге эчтәлекле 5.13 пункт өстәргә:

«5.13. Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә грантлар алучы хәрби хезмәткә (алга таба - мобилизация буенча хәрби хезмәт) чакырылган яисә грант алучы тарафыннан 2022 елдан башлап төзелгән Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә контракт буенча хәрби хезмәт узылган очракта (алга таба тиешенчә - контракт буенча хәрби хезмәт узу, хәрби хезмәт узу турында контракт) килешү буенча йөкләмәләрне үтәү мобилизация буенча хәрби хезмәт узу яки контракт буенча хәрби хезмәт узу вакытына туктатыла грант бирү нәтиҗәсенә ирешү срокларын, грант бирү нәтиҗәсенең мәгънәсен киметү мөмкинлеге белән грант бирү нәтиҗәсенә ирешү мөмкин булмаган очракта һәм (яисә) грант бирү нәтиҗәсенә ирешү, шулай ук, вәкаләтле орган килештереп, гранттан файдалану срокларын яисә гранттан баш тарту срокларын озайту, шулай ук, гранттан файдалану срокларын озайту яисә гранттан, штрафлы санкцияләр кулланмыйча, гранттан баш тарту срокларын озайту белән.»;

түбәндәге эчтәлекле 5.14 пункт өстәргә:

«5.14. Грантны алучы вәкаләтле органга килешү гамәлдә булган вакытта мобилизация буенча хәрби хезмәттә булу яки хәрби хезмәт узу турындагы контрактның гамәлдә булу чорында булуын раслый торган документлар тапшыра, ләкин аны мобилизация буенча хәрби хезмәттә булу яисә хәрби хезмәт узу турындагы контрактның гамәлдә булу срогы тәмамланганнан соң 30 календарь көннән дә соңга калмыйча.»;

6.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Грантның файдаланылмаган калдыгы, грант алучы вәкаләтле органның тиешле таләбен алган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнгән 10 көн эчендә кире кайтарылырга тиеш. 10 көнлек срок бозылганда, вәкаләтле орган календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә грантның файдаланылмаган өлешен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә кире кайтару чараларын күрә..»;

Тәртипкә 1 нче кушымтада:

нумерация баш исемендә «яисә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына» сүзләрен «һәм (яисә) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына» сүзләренә алмаштырырга;

социаль эшкуарлар реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына яисә 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына субсидияләр рәвешендә грантлар бирүгә гариәа формасы таблицасында:

15 пунктның 2 графасына «(сумнарда)» сүзен өстәргә;

16 пунктның 2 графасына «(сумнарда)» сүзен өстәргә;

Тәртипнең 1 нче кушымтасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

Тәртипнең 3 нче кушымтасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

Тәртипкә 4 нче кушымтада:

нумерация баш исемендә «яисә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына» сүзләрен «һәм (яисә) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына» сүзләренә алмаштырырга;

беренче абзацта «яисә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына» сүзләрен «һәм (яисә) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «яисә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына» сүзләрен «һәм (яисә) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына» сүзләренә алмаштырырга;

Тәртипкә 5 нче кушымтада:

нумерация баш исемендә «яисә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына» сүзләрен «һәм (яисә) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына» сүзләренә алмаштырырга;

беренче абзацта «яисә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына» сүзләрен «һәм (яисә) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Социаль эшкуарлар реестрына
кертелгән кече һәм урта эшкуарлык
субъектларына яисә 25 яшькә кадәрге
(25 яшьне кертеп) физик затлар
тарафыннан төзелгән кече һәм урта
эшкуарлык субъектларына
субсидияләр рәвешендә грантлар бирү
тәртибенә 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 17 май, 604 нче
карары редакциясендә)

Форма

Гарантия хаты

________________________________________________________________
(юридик затның исеме, шәхси эшкуарның Ф.И.Ат.ис. (соңгысы - булганда))

(алга таба - гариза бирүче) йөзендә ______________________________________
(вәкаләтле зат вазыйфасы, Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

________________________________________________________________
(устав, Шәхси эшкуарның төп дәүләт теркәве номеры (ОГРИП) таныклыгы, ышанычнамә реквизитлары)

нигезендә эш итүче моның белән конкурс нигезендә сайлап алу үткәрелергә планлаштырыла торган айның 1енә түбәндәгеләрне гарантияли:

салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле 3 мең сумнан арткан салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмавын;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлары, шулай ук Татарстан Республикасы каршында акча йөкләмәләре буенча вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычлары булмау;

заявка бирүче юридик зат үзгәртеп оештыру (башка юридик затның заявка бирүчесенә кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмавын, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәвын, аның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмавын, ә сайлап алуда катнашучы индивидуаль эшкуар үз эшчәнлеген индивидуаль эшкуар буларак туктатмавын;

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә

25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль эшкуарлар реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына яисә 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 12 октябрь, 971 нче карары белән расланган Социаль эшкуарлар реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына яисә 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибенең 1.4 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмавын;

заявка бирүченең Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баруын;

заявка бирүченең Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түләвен;

социаль эшкуарлар реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен:

кече һәм урта эшкуарлык субъекты «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 24.1 статьясындагы 3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә социаль предприятие дип танылган һәм аның турында мәгълүмат агымдагы календарь елның 10 июленнән 31 декабренә кадәр кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән;

кече һәм урта эшкуарлык субъекты социаль предприятие дип беренче тапкыр танылган, социаль эшмәкәрлек өлкәсендә эшчәнлек алып бару юнәлеше буенча заявка бирелгән көнгә кадәр ел дәвамында белем бирү программасы яки акселерация программасы кысаларында укуда булган яки социаль предприятие статусын раслаган, заявка биргән көнгә элек эшләнгән проектны гамәлгә ашыра;

25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен:

кече һәм урта эшкуарлык субъекты 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик зат тарафыннан төзелгән (25 яшькә кадәрге физик зат (25 яшьне кертеп) грант алу өчен документлар тапшыру вакытына индивидуаль эшкуар яисә юридик зат буларак теркәлгән, 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) бер яисә берничә физик зат устав (җыелма, акционер) капиталында катнашу өлеше (суммар өлеше) 50 проценттан артып китә);

кече һәм урта эшкуарлык субъекты эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру юнәлеше буенча грант алган вакытка кадәр ел дәвамында белем бирү программасы яки акселерация программасы кысаларында укуда булган.

___________________ __________________________________________________

(имзасы) (Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

М.У. (булганда)
20___ ел, «___» __________

____________________________________

Социаль эшкуарлар реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына яисә 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибенә 3 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 17 май, 604 нче
карары редакциясендә)

Форма

Проект

| | | |
|---|---|---|
| 1.1. | Социаль предприятие дип беренче тапкыр танылган кече һәм урта эшкуарлык субъекты | |

| | | |
|---|---|---|
| 1.2. | Социаль предприятие статусы расланган кече һәм урта эшкуарлык субъекты | |

| | | |
|---|---|---|
| 1.3. | 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъекты | |

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Заявка бирүче (тулы исеме):<br>Индивидуаль эшкуарның Ф.И.Ат.ис. (атасының исеме – булганда) / Юридик затның исеме | |
| 2. | Статусы:<br>Индивидуаль эшкуар / юридик затның оештыру-хокук формасы | |
| 3. | ИНН | |
| 4. | Теркәлү датасы: | |
| 5. | Заявка бирүченең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайты (сылтама): | |
| 6. | Заявка бирүченең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге социаль челтәрләре (сылтама) | |
| 7. | Проект җитәкчесе:<br>Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда), вазыйфасы (әгәр заявка бирүченең штат хезмәткәре булса) | |
| 8. | Проектның исеме | |
| 9. | Проектның максатчан аудиториясе: | |
| 10. | Проектның әһәмиятен нигезләү | |
| 11. | Проектның максаты | |
| 12. | Проектны тормышка ашыру географиясе: | |
| 13. | Проектны тормышка ашыру срогы (грант бирелгән елдан соң килә торган елның 1 июленә кадәрге дата күрсәтелә) | |

| | | |
|---|---|---|
| 14. | Проектны тормышка ашыруга каралган чыгымнар (проектның гомуми бюджеты, сумда) | |
| | шул исәптән: | |
| 14.1. | Проектны тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны финанслашу күләме (проектны тормышка ашыруга каралган чыгымнар күләменең кимендә 25 проценты, сумда) | |
| 14.2. | Грант акчасы (сумда) | |

Грант бирү нәтиҗәсе

| | | |
|---|---|---|
| 1.1. | Һөнәри керемгә салым түләүчеләр булмаган грант алучылар өчен – штат расписаниесе (яисә башка гамәлдәге документ) нигезендә штат санын кимендә бер берәмлеккә арттыру | |

| | | |
|---|---|---|
| 1.2. | Һөнәри керемгә салым түләүче грант алучылар өчен – һөнәри керемнәргә салым салына торган, килешү төзелгән көннән алынган керемнәрнең гомуми суммасы кимендә 10 000 сум күләмендә | |

Проект буенча чыгымнар:

| Т/с | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 12 октябрь, 971 нче карары белән расланган Социаль эшкуарлар реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына яисә 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибенең 1.4 пункты нигезендә чыгымнар юнәлеше | Планлаштырылган чыгымнарны (расшифровка, грант чаралары исәбеннән планлаштырыла торган чыгымнарны нигезли торган документлар*) тасвирлау | Субсидияләр алган | Грант акчасы, сум | Үз акчасы, сум | Проектның гомуми бюджеты, сум |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | | | |
| 2. | | | | | | |
| ... | | | | | | |

*Проект буенча планлаштырыла торган чыгымнар тиешле исәп-хисаплар һәм документлар (шартнамәләр, коммерция тәкъдимнәре, интернет кибетләр мәгълүматлары һ.б.) белән расланырга тиеш.

Проектка өстәмә рәвештә заявка бирүче эшчәнлекне үстерү планы төзелгән елдан соң килә торган өч елга әлеге планны (ирекле рәвештә) һәм проект буенча төп чаралар графигын терки.

20__ ел, «__» __________

Мөрәҗәгать итүче ______________ ______________________________________
(имзасы) (Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

М.У. (булганда)

_________________________________